**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Балтач авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Балтач авылы №**49** «**08**» апрель **2021** ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең **2020** елның **14** апрелендәге**163** номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлегенең бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлегенең бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (**24.04.2020** № **165**, **15.06.2020** № **172**, **04.12.2020** № **14**, **22.11.2021** № **38**карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, **2021** елның **29 11** декабрендәге **384**-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм **2022** елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль закон нигезендә,

**Балтач авыл җирлеге карар итте:**

**1.** Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең **2020** елның **14** апрелендәге **163** номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлегенең бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлегенең бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә (**24.04.2020** № **165**, **15.06.2020** № **172**, **04.12.2020** № **14**, **22.11.2021** № **38** карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1. 6** статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа унберенче абзац өстәргә:

«гражданнарның бюджет процессында катнашуы;»;

б) унберенче - ундүртенче абзацларны уникенче - унбишенче абзацлар дип санарга.

**1.2. 20** статьяда:

а) **2** пунктта «җирле бюджет кытлыгы,» сүзләреннән соң «инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының тиешле ел ахырына файдаланылмаган өлеше күләменнән тыш,» сүзләрен өстәргә;

б) **3** пунктта «җирлекнең бурыч йөкләмәләре» сүзләреннән соң «, инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының файдаланылмаган калдыгы күләменнән тыш,» сүзләрен өстәргә.

**1.3. 55** статьяның өченче өлеше үз көчен югалткан дип танырга.

**1.4. 58** статьяның **3** пунктында «әгәр Россия Федерациясе Бюджет кодексында башкасы каралмаган булса» сүзләрен өстәргә.

**2.** Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: **http://pravo.tatarstan.ru** һәм Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга: **http://aznakayevo.tatar.ru**.

**3.** Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай районы авыл җирлегенең бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Л.Л.Хәбипов